| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2022 Иске Эсләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елда җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2022 елның 01 февраленнән 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елга якыннары, ире (хатыны), законлы вәкиле булган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елга якыннары, ире

(хатыны), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 01 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Әхмәтов Д.М.

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Иске Эсләк  авыл
җирлеге Башкарма комитетының
31.01.2022 № 1
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елга якыннары, ире (хатыны), законлы вәкиле булган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Бәясе *(сум)* |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2982,51 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка күчерү | 732,01 |
| 4. | Кабер казу һәм җирләү | 3250,16 |
| | **Барлыгы** | **6964,68** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Иске Эсләк  авыл
җирлеге Башкарма комитетының
31.01.2022 № 1
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елга якыннары, ире (хатыны), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Бәясе *(сум)* |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Кәфенләү | 536,43 |
| 3. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2687,97 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка күчерү | 659,40 |
| 5. | Кабер казу һәм җирләү | 3080,88 |
| | **Барлыгы** | **6964,68** |